РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная,дом 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№19

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2021 елның 08 ноябрендә кабул ителгән 22нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.08.2024 елгы 289-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге чикләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында" 08.11.2021 елда 22нче номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 4.6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.6.3. Планнан тыш күчмә тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»31.07.2020 №248 - ФЗ Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

1.2. 4.9.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.9.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Положениедәге 4.2.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел ".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов